ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.03.2023 Баулы шәһәре №64

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 27 декабрендәге 344 номерлы карары белән расланган Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә Баулы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Субсидияләр бирүне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 22 декабрендәге 2385 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 27 декабрендәге 344 номерлы карары белән расланган Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә Баулы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (2020 елның 8 маендагы № 101 номерлы, 2020 елның 18 маендагы 85 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче “Субсидия алу хокукына ия юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар категорияләре” бүлегендә:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-транспорт оешмасы чит ил юридик заты булырга тиеш түгел, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә активлар белән арадаш (офшор) биләү өчен кулланыла торган дәүләтләр һәм

территорияләр исемлегенә кертелгән (алга таба - офшор компанияләре) дәүләт яисә территориядә теркәлгән, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яисә читләтелгән (өченче зат аша) катнашуы 25 процентган артып киткән Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) булырга тиеш түгел. Офшор компанияләрнең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә офшор компанияләренең ачык акционер җәмгыятьләр капиталында (шул исәптән халыкара компания статусы белән) турыдан-туры һәм (яисә) турыдан-туры катнашуы исәпкә алынмый, акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган сатуларга мөрәҗәгать итә, шулай ук күрсәтелгән гавами акционер җәмгыятьләр капиталында катнашу аша гамәлгә ашырылган башка Россия юридик затларының капиталында читләтеп катнашуы исәпкә алынмый.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров